**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**“ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ КАРАБАШ БИСТӘСЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**АЛТМЫШЫНЧЫ СЕССИЯ**
**2нче КАРАР**

Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе 2019 ел, 19 июнь

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге**
**җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен**
**Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турындагы**
**нигезләмәне раслау турында**

---

2007 елның 2 мартында кабул ителгән “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы “25-ФЗ Федераль Законына, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы кодекска туры китереп, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турындагы нигезләмәне расларга (1нче кушымта).
2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында күрсәтергә һәм “Интернет” челтәрендә Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе”**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **М.Т. МИНХӘЙДӘРОВ**

1нче кушымта
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе”
муниципаль берәмлеге Советының
60нчы сессиясенең 2нче карарына
2019 ел, 19 июнь

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**“Шәһәр тибындагы Карабаш бистәсе” муниципаль берәмлеге**
**җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрен**
**Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында**
**Нигезләмә**

1. Бу Нигезләмә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта муниципаль хезмәткәрнең гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе буенча түләү очракларын, тәртибен һәм күләмен билгели (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе).

2. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә керешкән көненнән алып, муниципаль хезмәттән азат ителгән көнен дә кертеп, аның муниципаль хезмәттә булган чорында гомере һәм сәламәтлеге дәүләт тарафыннан мәҗбүри иминиятләштерелә.

3. Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүендә иминиятләштерүче булып муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт үтә торган җирле үзидарә органнары яки башка муниципаль органнар тора (алга таба – иминиятләштерүчеләр).

4. Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе буенча страховкалаучылар булып (алга таба – страховкалаучылар) мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе белән шөгыльләнү өчен лицензиясе булган иминият оешмалары тора ала.

Страховкалаучыларны сайлау Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларда товарлар, эш, хезмәтләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда каралган тәртиптә башкарыла.

5. Иминият килешүе иминиятләштерүче һәм страховкалаучы арасында иминиятләштеререлә торган зат файдасына (файда күрүчегә), Россия Федерациясе законында каралган тәртиптә тәүлекнең 24 сәгатендә дә иминият яклавын тәэмин итеп, бер календарь елга төзелә.

Әлеге Нигезләмәнең 7нче пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен иминият килешүендә файда күрүчеләр страховкалаучы тарафыннан билгеләнә.

Иминият килешүендә файда күрүчеләр сыйфатында страховкалаучы тарафыннан күрсәтелергә тиешләр:

иминиятләштерелгән затның үлеме көненә аның белән рәсми никахта торган ире (хатыны);

иминиятләштерелгән затның әти-әнисе (уллыкка алган кешеләр), әбисе һәм бабасы – иминиятләштерелгән затның әти-әнисе булмаган очракта һәм алар аны кимендә өч ел тәрбияләп караган булсалар;

иминиятләштерелгән затның үги әтисе, үги әнисе – иминиятләштерелгән затның әти-әнисе булмаган очракта һәм алар аны кимендә биш ел тәрбияләп караган булсалар;

иминиятләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән балалары, яки 18 яшькә җиткәнче инвалид булган аннан олырак балалары, шулай ук, оештыру-хокукый формасы нинди булуга һәм милекчелекнең нинди формасында булуга карамастан, уку йортларында белем алучы балалары, әмма 23 яшьтән олыраклар түгел;

иминиятләштерелгән затның каравында булган кешеләр.

Файда күрүчеләр иминиятләштерү килешүендә гражданлык хезмәткәре тарафыннан аны страховкалаучы билгеләгән тәртиптә биргән мәгълүмат нигезендә күрсәтеләләр. Иминиятләштерү килешүендә файда күрүчеләр күрсәтелмәгән булса, иминиятләштерелгән затның мирасчылары гражданлык законнарында билгеләнгән тәртиптә танылалар.

6. Муниципаль хезмәткәрне иминиятләштерү килешүендә каралган срок беткәнче муниципаль хезмәттән азат итү әлеге муниципаль хезмәткәргә мөнәсәбәттә, ул муниципаль хезмәттән азат ителү датасыннан башлап, килешүнең туктатылуына китерә. Муниципаль хезмәткәргә мөнәсәбәттә иминиятләштерү килешүе вакытыннан алда туктатылса, иминиятләштерүче муниципаль хезмәткәрнең иминият премиясен, күрсәтелгән нигездә, иминият килешүенең гамәлдә булган калган срогына пропорциональ рәвештә, әлеге Нигезләмәнең 12нче пунктында билгеләнгән тәртиптә страховкалаучыга кайтарып бирә.

7. Иминиятләштерү очраклары булып торалар:

1) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт итү вакытында үлеме, шулай ук муниципаль хезмәттә вакытта алган имгәнүе, җәрәхәтләнүе яки авыруы сәбәпле, муниципаль хезмәттән азат ителүдән соң бер ел дәвамында;

2) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт итү вакытында инвалидлык алуы, шулай ук муниципаль хезмәттә вакытта алган имгәнүе, җәрәхәтләнүе яки авыруы сәбәпле, муниципаль хезмәттән азат ителүдән соң бер ел дәвамында;

3) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт итү вакытында алган имгәнүе я тән җәрәхәтләре алуы;

4) иминиятләштерелгән затның соңрак эш бирүче вәкиленең инициативасы белән хезмәт контрактын өзүгә, муниципаль хезмәттәге вазыйфасыннан азат ителүгә, һәм медицина йомгаклары буенча муниципаль хезмәттән чыгарылуга нигез булып тора торган һәм инвалидлык бирелүгә бәйле булмаган чиргә дучар булуы.

8. Иминиятләштерелгән затка (файда күрүчеләргә) түләнә торган иминият суммасының күләме муниципаль хезмәткәрнең айлык окладын тәшкил итә торган биләгән вазыйфасына туры китереп түләнгән окладын һәм чин классына күрә айлык өстәмәләрен исәпкә алып билгеләнә (алга таба – оклад).

9. Иминият очраклары килеп туган очракларда иминият суммасы түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт итү вакытындагы үлеме, шулай ук муниципаль хезмәттә вакытта алган имгәнүе, җәрәхәтләнүе яки авыруы сәбәпле, муниципаль хезмәттән азат ителүдән соң бер ел дәвамында – 26,25 оклад күләмендә. Әлеге иминият суммасы файда күрүчеләргә тигез өлешләрдә бүлеп бирелә;

2) иминиятләштерелгән затның муниципаль хезмәт итү вакытында инвалидлык алуы, шулай ук муниципаль хезмәттә вакытта алган имгәнүе, җәрәхәтләнүе яки авыруы сәбәпле, муниципаль хезмәттән азат ителүдән соң бер ел дәвамында:

I төркем инвалидка – 17,5 оклад;

II төркем инвалидка – 12,25 оклад;

III төркем инвалидка – 10,5 оклад;

3) иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәт итү вакытында авыр имгәнсә я авыр тән җәрәхәтләре алса – 7 оклад, җиңел дәрәҗәдә булса – 1,75 оклад. Тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнү һәм җәрәхәтләнүләрнең (контузия алу, яралану, тән җәрәхәтләре алу) авыр, яисә җиңел булу дәрәҗәсе 1998 елның 28 мартында кабул ителгән "Хәрби хезмәткәрләрне, хәрби җыенга чакырылган гражданнарны, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының, дәүләт янгынга каршы хезмәт органнарының, җинаятьчелек-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнарының рядовой яки җитәкчелек составындагы затларының, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләренең гомерләрен һәм сәламәтлекләрен мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе турында"гы №52-ФЗ Федераль законында күрсәтелгән тәртиптә билгеләнә";

4) иминиятләштерелгән затның соңрак эш бирүче вәкиленең инициативасы белән хезмәт контрактын өзүгә, муниципаль хезмәттәге вазыйфасыннан азат ителүгә, һәм медицина йомгаклары буенча муниципаль хезмәттән чыгарылуга нигез булып тора торган һәм инвалидлык бирелүгә бәйле булмаган чиргә дучар булуы очрагында – 8,75 оклад.

Әгәр иминиятләштерелгән зат муниципаль хезмәттә булган вакытта, яисә муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң бер ел вакыт эчендә федераль медицина-социаль экспертиза үткәндә аның инвалидлык төркеме күтәрелә икән, иминият суммасының күләме яңа билгеләнгән инвалидлык төркеме белән элекке инвалидлык төркеме өчен тиеш булган суммалар арасындагы окладлар күләменең аермасы кадәр арттырыла.

Әгәр иминиятләштерелгән затка иминият очрагына бәйле рәвештә иминият суммасы түләнгән булса, ә ел дәвамында аның сәламәтлеге начарланса, яисә үлем очрагы була калса, элек түләнгән сумманы чигереп, өстәмә иминият түләве (иминият түләүләре) бирелә.

Иминиятләштерелгән һәр зат өчен бирелә торган иминият премиясенең күләме иминиятләштерү килешүе нигезендә билгеләнә һәм ул иминиятләштерелгән затның килешү төзегән вакытта булган окладының 8, 75 процентыннан артып китә алмый.

10) Иминиятләштерүче мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүе буенча иминият суммасын түләүдән азат ителә, әгәр:

1) иминият очрагының иминиятләштерелгән затның җәмгыять өчен куркыныч гамәл кылган вакытта барлыкка килүе суд тарафыннан танылса;

2) иминият очрагының иминиятләштерелгән затның алкоголь, наркотик, яисә токсик агулануына турыдан-туры бәйле булганлыгы суд тарафыннан расланса;

3) иминият очрагының иминиятләштерелгән затның үз сәламәтлегенә аңлы рәвештә зыян салуы, яисә үз-үзенә кул салуы суд тарафыннан ачыкланса.

Әгәр иминиятләштерелгән затның үлеме аның үз-үзенә кул салу дәрәҗәсенә җитерелүенең нәтиҗәсе икәнлеге суд тарафыннан расланса, страховкалаучы иминият акчасын түләүдән азат ителми.

Страховкалаучының иминият акчасын түләүдән баш тартуы турындагы карары кабул ителгәч, иминиятләштерелгән затка (файда күрүчеләренә) һәм иминиятләүчегә иминият акчасын түләү өчен билгеләнгән срокта, мәҗбүри рәвештә мотивацияле сәбәпләрен күрсәтеп, язма формада тапшырыла.

11. Иминият түләүләре иминиятләштерелгән затның (файда күрүченең) гаризасы һәм иминият очрагы килеп тууны раслаган документлар нигезендә страховкалаучы тарафыннан бирелә.

Иминият түләүләрен башкару турында карар кабул итү турындагы документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе иминиятләштерү килешүендә билгеләнә.

Иминият суммасын иминиятләштерелгән затка түләү страховкалаучы тарафыннан иминиятләштерү килешүләренең башка төрләренә бәйсез рәвештә башкарыла.

Иминият суммасы иминиятләштерелгән затка (файда күрүчегә) страховкалаучы тарафыннан иминиятләштерү килешүендә билгеләнгән тәртиптә, тиешле суммада сумнарда бирелә.

Иминият суммасын түләү әлеге түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар алынганнан соң 10 көн эчендә башкарыла.

12. Әгәр иминиятләштерү килешүе гамәлдә булган вакытта иминиятләштерелгән затның окладының күләме, саны үзгәргән булса, әлеге вәзгыятькә бәйле рәвештә алып җиткерелмәгән, яисә артык бирелгән акча өстәп түләнергә, яисә кире кайтарып бирелергә тиеш. Иминиятләштерү килешүе төзелгән

якларның килешүе буенча әлеге суммалар чираттагы иминиятләштерү килешүе чорына иминият взносларының күләмен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминиятләштерелүче затның иминият взносларын түләү вакыты иминиятләштерү килешүендә билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятләштерүен финанслау чыгымнары муниципаль берәмлек бюджеты исәбенә башкарыла.